*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 40**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Борын тартыкларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [б], [п]
   ә) [к], [г]
   б) [қ], [ғ], [х], [ң]
   **в) [м], [н], [ң]**

2. Татар алфавитындагы 10 нчы хәрефне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Е
   ә) Ж
   **б) Җ**
   в) З

3. Бирелгән фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Йокы капчыгы***
   а) күп әйбер салынган капчык
   ә) буш капчык
   б) йокы яратмаучы
   **в) йокы яратучы**

4. Бер мәгънәгә генә ия булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) суыткыч**
   ә) койрык
   б) тел
   в) кыңгырау

5. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бозгыч, бозлавык
   ә) сөт, сөлге
   б) кис, кистек
   **в) бит, битлек**

6. Вакыт рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) җәй
**ә) кышын**
б) көзге
в) күп

7. Билгеле үткән заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
**а) йөгерде**
ә) йөгергән
б) йөгерә
в) йөгерер

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Бер рәхмәт мең бәладән коткарыр*. (Мәкаль)
а) бер
**ә) рәхмәт**
б) бәладән
в) коткарыр

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган хәрефләрне һәм сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Хәзерге татар әдәби телендә 40 **аваз** бар. [э] авазы сүз һәм иҗек башында – **э** хәрефе белән, иҗек уртасында һәм ахырында **е** хәрефе белән белдерелә. Мәгънәләре тәңгәл яки бер-берсенә якын торган сүзләр **синоним** сүзләр дип атала. Тамыр һәм ясагыч кушымча сүзнең **нигезен** тәшкил итә. Татар телендә **җыю** саны саналмышыннан башка кулланыла.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

*глубина – тирәнлек* *пояс – билбау*
*орнамент – бизәк* *личность – шәхес*

2. “Минем туган җирем” дигән темага 10 җөмләдән торган инша языгыз. **(14 балл)**